ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

31.08.2024 № 813

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда арендага бирелә торган күчемле һәм күчемсез милеккә бүлеп түләү срогын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт яки муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында, һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы милкендә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда арендага бирелә торган күчемле һәм күчемсез милеккә бүлеп түләү срогы күчемсез милек өчен 5 (биш) ел, һәм күчемле милек өчен 3 (өч) ел тәшкил итә.

2. Арендалана торган сатып алына торган күчемле һәм күчемсез милеккә түләү тәртибен (бер тапкыр яки бүлеп түләү), шулай ук бүлеп түләү срогын сайлау хокукы әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә, арендага бирелә торган милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яки урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып, рәсми рәвештә игълан итәргә.

4. Әлеге карар аны рәсми рәвештә игълан иткән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе С. М. Минһаҗевка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин